ТАТАР ХАЛЫК ӘКИЯТЛӘРЕ МОТИВЛАРЫ БУЕНЧА

# КАМЫР БАТЫР

ПО МОТИВАМ ТАТАРСКИХ НАРОДНЫХ СКАЗОК



*Идел буе халыклары дус һәм үзара килешеп яшиләр. Һәр милләт кешесе үзенең данлы һәм үзенчәлекле мәдәнияте белән горурлана. Китапта Идел буе халыкларының бай милли мәдәнияте аларны рухи яктан берләштерүче Батыр образында бирелгән. Шул ук вакытта һәр халыкның үз Батыры бар.*

www.волжскиебогатыри.рф

# КАМЫР БАТЫР

**ТАТАР ХАЛЫК ӘКИЯТЛӘРЕНӘ НИГЕЗЛӘНЕП**



# КАМЫР БАТЫР

**ПО МОТИВАМ ТАТАРСКИХ НАРОДНЫХ СКАЗОК**



Борын-борын заманда яшәгән, ди, карт белән карчык. Алар бик рәхәт гомер кичергәннәр, ләкин, ни кызганыч, балалары булмаган... Көннәрдән бер көнне карчык бер кисәк камыр алган да: «Улыбыз булмады... Камырдан булса да малай сыны ясыйм әле!» – дигән.

Малай сынын ясаган да эскәмиягә куйган. Үзе өй эшләренә тотынган – сыер саварга чыгып киткән. Ә карт ишегалдында утын ярган.

Өйгә керсәләр – шаккатарлык хәл. Үз күзләренә үзләре ышанмыйлар: камырдан ясалган сынга җан кергән. Ул көлә-көлә уйнап утыра икән.

«Улыбызга нинди исем кушарбыз икән?» – дип сорый карчык. «Без бит аны камырдан ясадык, әйдә, Камыр булсын», – ди карт.

Жили в давние-предавние времена на свете старик со старухой. Хорошо жили, да вот беда – не было у них детей. Взяла как-то старуха кусок теста и говорит: «Нету у нас сыночка... Сделаем-ка себе мальчишку хоть из теста!»

Слепила она мальчика, положила его на лавку. Сама делом занялась – корову доить пошла. А старик во дворе дрова рубил.

Вернулись в дом и очень удивились. Стоят и глазам своим не верят: мальчик из теста ожил! На скамейке сидит, играет и смеётся.

«Как же нам сынка нашего назвать?» – старуха спрашивает. «Мы его из теста сделали, так пусть и зовётся Камыр*», – старик говорит.



*Камыр *(тат.)* – *тесто*



Малай көнләп түгел, сәгатьләп үсә башлый. Бер ай дигәндә, ел үсәсен үсә ул. Малайның көче дә көннән-көн арта бара.

Көннәрдән бер көнне ул урамга уйнарга чыга. Бер малайны күтәрүе була – аны агач башына очыртып җибәрә. Моны күреп, Камыр янына башкалар йөгерешеп киләләр. Аның белән көрәшеп, җиңәргә телиләр, ләкин булдыра алмыйлар. Ул аларны да агач башына ыргыта. Авыл урамы буйлап барганда, юлында очраган бар кешене кайсын түбәгә, кайсын койма аша ыргыта икән бу. Ә тегермәнчене исә тегермән башына кадәр алып бәрә.

И стал Камыр расти не по дням, а по часам. За один месяц так вымахал, как у другого и за год не выйдет. И сил у мальчишки с каждым днём прибывает.

Вышел он как-то раз на улицу с ребятами поиграть. Поднял одного дружка и забросил его на дерево. Подбежали к Камыру другие. Побороть хотели, на землю повалить, да не смогли. Он и их на дерево закинул. А потом кого в деревне ни встретит – то на крышу, то через забор, а мельника аж на мельницу забросил.



Кешеләр бу хәлләрдән соң ризасызлыкларын белдерә башлыйлар. Алар Камырның усаллык белән эшләмәвен, ә көчен кая куярга белмәгәннән шаяруын аңламыйлар, билгеле. «Аны хөкемгә тартырга кирәк!» – дигән таләп куя халык. Камырны ханга китерәләр һәм зарларын сөйлиләр, яклавын сорыйлар.

– Син бу кешеләрнең барысын берүзең шулай өскә чөйдеңме? – дип сорый хан.

– Әйе, – дип җавап бирә Камыр.

– Көчеңне изге эшкә сарыф итәргә телисеңме?

– Ничек була соң ул?

– Минем кызымны табарга кирәк иде. Беркөнне ул урамга йөрергә чыккач, кинәт кенә көчле җил чыкты да аны алып китте, – ди хан Камырга.



Люди, ясное дело, недовольны. Не поняли, что Камыр никому зла не желает, а просто забавляется, не ведая что творит. «Судить его!» – все закричали. Привели Камыра к хану, жалуются, защиты просят.

– Так ты что, один всех раскидал? – хан спрашивает.

– Да, – отвечает Камыр.

– А хочешь свою силу на доброе дело пустить?

– А как это?

– Нужно мою дочь найти, – говорит хан. – Гуляла она однажды, и вдруг поднялся сильный ветер и унёс её.



– Ярар, тик синең тимерчең миңа зур тимер күсәк ясасын, – ди Камыр.

Шулай килешәләр болар. Күсәк әзер булуга, баһадир юлга кузгала.

Кая барырга кирәклеген белмәгәнгә, күңеле кая тартса, шул якка китә бу. Күп җирләр үтә, күп җирләрне күрә: тауларга да менә, чүлне дә кичә, мәңгелек кар яткан җирләр аша да үтә. Тик кемнән генә сорамасын, хан кызы турында беркем дә берни дә белми. Көннәрдән бер көнне Камыр карурманга килеп керә. Шунда сазлык янында гына субай өстенә салынган кечкенә генә өй күрә ул. Өйнең ишеге аста була. Тәрәзәләреннән әллә нинди яшел ут төшә һәм коточкыч әшәке ис килә. «Нишләргә икән соң? Керим әле, эчәргә су сорыйм».



– Хорошо, – отвечает Камыр. – Пусть твой кузнец сделает мне большую железную дубину.

На том и порешили. И как только дубина была готова, отправился богатырь в путь.

Куда идти надо, он не знал, так что пошёл куда глаза глядят. Много мест повидал: и на горы забирался, и пустыню прошёл, и снега вечные. И кого ни спрашивал про ханскую дочь, никто не слыхал. Но забрёл как-то Камыр в лес дремучий. И видит у болота избушку на столбах. А дверь у неё – внизу. И свет в окнах горит зелёный и зловещий, и запах стоит такой противный. «Что ж делать? Пойду, водицы испить попрошу».



Камыр өйгә менсә, анда учак яна, аның өстенә зур казан асылган, ә эчендә яшел сыекча быгыр-быгыр кайный. Якында гына эреле-ваклы савытлар, шешәләр, ә диварларда киптерелгән үлән тамырлары. Ә казан янында бөкре, зур ыргаксыман борынлы һәм авызыннан озын, сары теше чыгып торган карчык кайнаша.

– Әбекәй, исәнме, – дип эндәшә Камыр. – Эчәргә су бирмәссеңме икән?

Карчыкның өстәлендә су салынган ике чүлмәк тора. Ул берсен ала да:

– Мә, эч. Кая болай юл тотасың? – дип сорый.

Камыр, тимер күсәген өстәлгә сөяп куеп, бер йотым су эчә дә:

– Хан кызын эзлим, – дип җавап бирә.

– Дию урлап киткән кызныммы?

– Ә син каян беләсең? – ди, гаҗәпләнә, Камыр. Һәм кинәт кенә аның аяклары хәлсезләнеп китә.

– Мин күп нәрсә беләм... – ди хуҗа карчык.



Поднялся Камыр в избушку. А там огонь пылает, и над пламенем огромный котёл висит, а в нём зелёная жижа бурлит. Вокруг баночки-пузырёчки, а на стенах сушёные корешки, мухоморы, мышки да лягушки висят. А возле котла – горбатая старуха с большим крючковатым носом и длинным жёлтым зубом, что изо рта торчит.

– Здравствуй, бабушка, – говорит Камыр. – Дай мне водицы попить.

На столе у старухи два кувшина с водой стояли. Взяла она один:

– Пей, путник. Куда путь держишь?

Прислонил Камыр дубину железную к столу, хлебнул малость:

– Дочь хана ищу.

– Которую Див похитил?

– А ты откуда знаешь? – удивился Камыр и почувствовал вдруг в ногах какую-то слабость.

– Я много чего знаю… – говорит хозяйка.



– Белсәң, кайдалыгын әйтеп кара, – дип сорый Камыр, аягүрә йокыга талып.

– Сиңа барыбер түгелмени? – ди карчык, хихылдап. – Көчсезләндерә торган су эчтең. Син инде хәзер минем әсирем.

Пәһлеванның башы әйләнә, ул чайкалып китә дә барып төшә. Хәтта өй селкенеп куя. Ләкин карчык иртәрәк сөенгән булып чыга: менә аның өстенә тимер күсәк килеп төшә һәм аны идәнгә китереп сылый, шундый итеп сылый – бердәнбер теше идән ярыгына кереп кысыла.

– Ярдәм ит! Үләм бит инде! – дип ыңгыраша ул.

– Син мине хәлсезләндердең бит... – ди Камыр, көчкә телен әйләндереп.

– Өстәлдә тагын бер чүлмәк бар! Суы башка аның... – дип кычкыра карчык.

Камыр көч-хәл белән тезләнә, кирәкле чүлмәкне табып, су эчә. Шундук ул үзендә көч сизә, аякларына торып баса, ләкин күсәкне алырга ашыкмый.



– И где же она? – Камыр спрашивает, а сам на ходу засыпает.

– А какая тебе разница? – старуха хихикает. – Теперь ты мой пленник, раз водицы испил, что сил лишает…

Закружилась у богатыря голова, пошатнулся он и упал. Аж избушка подскочила. Рано старуха радовалась: на неё железная дубина свалилась, да так к полу придавила, что единственный её зуб в половице застрял.

– Помоги!.. Помираю!.. – зашипела она.

– Ты ж сама меня сил лишила… – еле ворочая языком, говорит Камыр.

Старуха в пол кричит:

– Там, на столе, ещё один кувшин есть! С другой водой…

Еле-еле встал на колени Камыр, но нашёл кувшин и выпил из него. И сразу сила к нему вернулась. Вскочил он на ноги, но дубину убирать не стал.

– Скажешь, где дочь хана искать, тогда уберу.



– Хан кызын кайдан эзләргә икәнен әйт – шуннан соң алырмын, – ди.

Убырлы карчыкның башка чарасы калмый – ул үзе белгәннәрнең барысын да, хәтта кирәгеннән артыгын сөйләп бирә. Шуннан соң Камыр аның өстенә төшкән кусәкне күтәрә, карчыкка торырга ярдәм итә. Тик менә теше генә идән ярыгына кысылып кала.

Инде баһадир убырлы карчык сөйләгән Дию сараен эзләп китә. Кирәге чыга калса дип, теге тере һәм үле су салынган чүлмәкләрне дә үзе белән ала.

Көнне төнгә ялгап, шактый озак бара баһадир сарайга. Бик арыса, чүлмәктән тере су эчә һәм юлын дәвам итә. Сарай күренүгә, чүлмәктә калган соңгы йотым суны да эчә. «Бетте, бары тик үле су гына калды...» – ди ул үз-үзенә.

Капка янына килеп җитсә, ни күрсен: алтын көбә кигән һәм сугыш кораллары тоткан, алтын атка атланган, тик чылбыр богау салынган бер кызны күрә.

– Тукта, кем килә анда? – дип кычкыра моңа кыз.





Делать нечего – рассказала ведьма всё, что знала, и даже больше. Снял Камыр с неё дубину, помог старой подняться. Только вот зуб так и остался в полу торчать.

Пошёл богатырь искать замок Дива, про который колдунья сказала. И взял с собой на всякий случай те кувшины с живой и мёртвой водой.

Долго до замка добирался. Устанет – хлебнёт из кувшина с живой водой и опять в дорогу. Как дворец завидел, достал кувшин и последний глоток выпил. «Всё, осталась только мёртвая…» – сам себе говорит.

Подошёл он к воротам и видит девушку в золотых доспехах и на золотом коне, только в цепи закованную.

– Стой, кто идёт? – она кричит.

– Минем исемем Камыр. Ә син, сакчы, кем буласың?

– Мин хан кызы. Дию мине сарай сакларга мәҗбүр итә.

– Ә мине әтиең сине алып кайтырга дип җибәрде!

– Дию мине җибәрмәячәк. Ул исән чакта бу чылбырларны өзәрлек көч юк...

– Алай булганда, мин аның янына сөйләшергә киттем...

Кинәт аның алдында ишекләр ачылып китә, һәм Камыр зур бер бүлмәгә эләгә, бүлмә уртасында биш тимер багана тора. Камырның шулар арасына кереп басуы була, аңа багана артыннан Дию һөҗүм итә. Үзе яп-ябык, озын, тәне зәңгәр, күзләреннән ут чәчелә. Аның озын кылычы ялтыр-йолтыр килә. Камырның күсәге каршы тора, бирешми. Ләкин күсәк белән селтәнүе була, Дию шунда ук юкка чыга һәм яңадан – әле яннан, әле арттан – төрле баганалар артыннан һөҗүм итә. Камыр бөтерчек кебек әйләнә. Ул баганаларны җимермәкче була, әмма алардан бары тик очкын гына оча. Ә Дию һич кенә дә тынмый. Баһадир арый, хәлсезләнә башлый.



– Камыр меня зовут. А ты кто будешь, воин?

– Я дочь хана. Див заставляет меня дворец охранять.

– А меня за тобой твой отец послал!

– Див меня не отпустит. Пока он жив, цепей этих не разорвать.

– Что ж, тогда пойду к нему, поговорю…

Распахнулись двери, и очутился Камыр в огромном зале, посерёдке которого пять железных столбов стояло. Встал Камыр между ними, и тут же на него прямо из-за столба Див напал. Сам костлявый, длинный, кожа синяя, глаза огнём полыхают. Длинный меч его то и дело сверкал в воздухе. Дубина Камыра выдерживала. Но как только он пробовал ответить на удар, Див исчезал и снова нападал – то сбоку, то сзади, каждый раз из-за разных столбов являясь. Приходилось Камыру вертеться волчком. Он пытался разрушить столбы, но от них только искры разлетались. А Див всё не унимался. Стал богатырь уставать.







«Эх, менә хәзер тере су эчсәң иде! Үле су гына калды шул...» Шулчак Камырның башына бер уй килә. Кесәсеннән үле сулы чүлмәкне ала да, Дию аңа ташлангач кына, тегенең йөзенә сибә. Дию чайкалып китә, кылычы кулыннан төшә, һәм ул тезләнә. Камыр үзенең кусәген аның сыртына төшерә...

Хан кызы аны капка төбендә дулкынланып көтеп тора. Шулчак аның чылбырлары гөрселдәп җиргә төшә, ә алтын кораллары, киемнәре комга әйләнеп коелып бетә. Кинәт капка ачылып, сарайдан Камыр килеп чыга: «Инде әйдә, өйгә кайтыйк!» – ди ул.

Хан чиксез шатлана, кызын коткарган өчен Камырга рәхмәтләрен җиткерә һәм үзенә хезмәт итәргә тәкъдим итә. Баһадир кусәген җилкәсенә сала да:

– Миңа өйгә кайтырга вакыт, әти белән әни өйдән ерак китеп уйнарга рөхсәт итмиләр, – дип, өенә кайтып китә.





«Эх, сейчас бы живой водицы испить! Да одна мёртвая осталась…» Но тут Камыру пришла в голову мысль. Достал он из кармана кувшин с мёртвой водой и, когда Див бросился на него, плеснул тому в лицо.

Зашатался Див, выронил меч и упал на колени. А Камыр поднял свою дубину…

Дочь хана, волнуясь, ждала у ворот. И вдруг цепи на ней с грохотом попадали на землю, а золотые доспехи рассыпались в песок. Ворота отворились, и из замка вышел Камыр. «Ну что, пошли домой!» – сказал он.

Хан очень обрадовался, поблагодарил Камыра за спасение дочери и предложил служить в его страже.

Но богатырь, взвалив на плечо дубину, сказал, что ему надо домой: дескать, мать с отцом не разрешают далеко от дома играть.

Шуннан соң аны Камыр дип түгел, ә Камыр батыр дип йөртә башлыйлар. Бу вакыйга турында таралган хәбәр исә дошманнарны һәм төрле җен-пәриләрне әле бик күп еллар буе аның туган җирләренә якын җибәрми.

Татарларда «Батыр яуда беленер» дигән мәкаль менә шуннан алынган.





С тех пор все стали звать его не просто Камыр, а Камыр батыр. А история эта ещё долго отпугивала от его родных мест врагов и всякую нечисть.

Как говорится у татар, настоящий богатырь в бою проверяется.



www.волжскиебогатыри.рф

Руководитель проекта
**Азат Ганиев**

Художественный руководитель
**Дмитрий Гиацинтов**

Главный режиссёр
**Сергей Киатров**

Литературная редакция:
**Сергей Киатров, Алсу Низамеева, Гюльнара Фазлиахметова, Анна Белоброва, Борис Вайнер, Максим Ардашев, Фарида Ахметзянова**

Стилистика и дизайн персонажей
**Фёдор Соболев**

Художники-иллюстраторы:
**Татьяна Винникова, Георгий Хабаров, Ольга Волкова, Наиля Авдеева, Айк Саакянц, Дарья Митрофанова, Гулия Исмагилова, Евгения Федотова, Алексей Малетин, Анастасия Бронникова, Наталья Кочергина, Эльвира Шевцова, Гузель Гилазетдинова, Мария Соколова, Алла Анисимова, Аида Ромашова**

Технический директор
**Ильдар Низаметдинов**

Консультанты:
**Е. Н. Антипкина, Р. А. Бушков, К. Г. Васильев, Г. А. Глухова, М. А. Жулина, И. В. Зубов, Т. Э. Ибатиева, М. И. Иванова, М. Г. Кондратьев, М. З. Левина, К. А. Малышев, Л. С. Матросова, Х. Ю. Миннегулов, С. В. Новиков, В. Г. Родионов, И. Н. Рябов, О. А. Третьяков, С. Н. Чаркина, И. И. Шарипов, К. Г. Яковлев**

Специалисты по этнографии:
**Татьяна Прокина, Владимир Кудрявцев, Семён Виноградов, Мария Ходорева**

Татарское детское издательство.
420124, г. Казань, ул. Сулеймановой, 5.
www.tdpress.ru


ТОИ
ЭМОЦИОНАЛЬНЫЙ ИНТЕЛЛЕКТ
ТАТАРСКОЕ ДЕТСКОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО • ТАТАР БАЛАЛАР НӘШРИЯТЫ
Татармультфильм